**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА СТАРОАЛЬМЕТЬЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ӘЛМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Иске Әлмәт ав. **КАРАР**

«01» март 2024 ел № 1

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Яңа Әлмәт авылына элек расланган карарларга үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге башлыгы

**КАРАР ИТТЕ**:

1. 2024 елның 15 мартында Татарстан Республикасы, Нурлат районы, Иске Әлмәт авылы, Октябрь урамы, 19 йорт адресы буенча урнашкан Иске Әлмәт мәдәният йорты бинасында 10 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Яңа Әлмәт авылында яшәүчеләрдән үзара салым кертү мәсьәләсенең элек расланган карарларына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә:

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Яңа Әлмәт авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 15 ноябрендәге 3 номерлы карары;

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Яңа Әлмәт авылында гражданнар Җыенының 2023 елның 15 ноябрендәге 4 номерлы карары.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Яңа Әлмәт авылы гражданнары җыенын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге башлыгы һәм Иске Әлмәт авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

3.1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Яңа Әлмәт авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 15.11.2023 елның 3 номерлы карарының 1 һәм 2 пунктларына үзгәрешләр кертергә ризамы, аны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Яңа Әлмәт авылында гражданнар җыены узган, гражданнар җыены нәтиҗәләре – гамәлдә дип танырга.

2. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Яңа Әлмәт авылы территориясендә яшәүче һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның һәм тол хатыннарыннан тыш, 2024 елда 1500 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы? " дигән сорау буенча карарны танырга, һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Яңа Әлмәт авылы торак пункты чикләрендә юл полотносы профилен үзгәртеп, юлларны карап тоту, вак ташлар сатып алу, юл полотносы профилен үзгәртү өчен хезмәт күрсәтү.
- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Яңа Әлмәт авылы торак пункты чикләрендә юлларны карап тоту, грейдировкалау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм алга таба таш җәю өчен тыгыз нигез салу,
- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Яңа Әлмәт авылы территориясен чистарту һәм төзекләндерү.

3.2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Яңа Әлмәт торак пунктында гражданнар Җыенының 15.11.2023 ел, № 4 карарына аны түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәрешләр кертергә ризамы:

«2024 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Яңа Әлмәт авылы территориясендә яшәүче һәр балигъ булган кешедән 1500 сум күләмендә үзара салым кертү чараларын кертергә, 1 гр инвалидлардан Бөек Ватан сугышында катнашучыларның һәм тол хатыннарыннан тыш, һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Яңа Әлмәт авылы торак пункты чикләрендә юл полотносы профилен үзгәртеп, юлларны карап тоту, вак ташлар сатып алу, юл полотносы профилен үзгәртү өчен хезмәт күрсәтү.
- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Яңа Әлмәт авылы торак пункты чикләрендә юлларны карап тоту, грейдировкалау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм алга таба таш җәю өчен тыгыз нигез салу,
- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлегенең Яңа Әлмәт авылы территориясен чистарту һәм төзекләндерү.

4. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ һәм Иске Әлмәт авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында гражданнар җыены уздырылганга кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Иске Әлмәт авыл җирлеге башлыгы Р.Г. Хисамов